**СОВЕТ БОЛЬШЕБИТАМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422725, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Большой Битаман, ул. Московская, 2В

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ БИТАМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422725, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Олы Битаман авылы, Мәскәү ур., 2В

Тел./факс: +7(84365) 62-8-47, e-mail: Bbit.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**28 июнь 2024 е.** **№ 95**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 30 октябрендәге 151 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында», 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге Советының 2019 елның 30 октябрендәге 151 номерлы карары белән расланган (09.10.2020 №7, 09.12.2020 №15, 14.09.2021 №29, 15.05.2023 №66, 21.09.2023 № 70 каралар редакциясендә) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында:

1.1. 5 маддәнең 1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктча белән тулыландырыга: 12) яллаучы (эш бирүче) вәкиленә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында " 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетадагы белешмәләрнең аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш(алга таба-анкетада булган мәгълүматлар)

1.2. 6 маддәнең 1 пунктының 8 пунктчасынтүбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) ул үткән чорда ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәү турында документлар һәм (яисә) мәгълүматлар бирмәүче, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә);»;

1.3. 14 маддәнең 3 пунктының 2 пунктчасын түбәндәгечә бәяг итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета;»;

1.4. 14 маддәнең 4 пунктында “Белешмәләр” сүзен «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)» сүзләре белән тулыландырыга.

2. Әлеге карарны http://vysokaya-gora.tatarstan.ru. адресы буенча Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә һәм http://pravo.tatarstan.ru адресу буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә (халыкка чыгарырга)

3. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Совет рәисе урынбасары,
авыл җирлеге башлыгы урынбасары Г.Н.Ибраһимова